**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 20 февралендәге 509 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 10 июлендәге 2680 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Казан шәһәренең электромобильләр өчен парковка рөхсәтләре реестрына электромобиль өчен парковка рөхсәте турында язма, электромобиль өчен парковка рөхсәте турындагы язманы үзгәртү һәм электромобиль өчен парковка рөхсәтенең гамәлдә булу вакытын озайту турында мәгълүматлар кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы федераль закон нигезендә, электромобильләр үсешенең популярлашуын исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 10 июлендәге 2680 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Казан шәһәренең электромобильләр өчен парковка рөхсәтләре реестрына электромобиль өчен парковка рөхсәте турында язма, электромобиль өчен парковка рөхсәте турындагы язманы үзгәртү һәм электромобиль өчен парковка рөхсәтенең гамәлдә булу вакытын озайту турында мәгълүматлар кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 27 маендагы 2184 номерлы, 2019 елның 2 августындагы 2759 номерлы, 2020 елның 17 декабрендәге 3735 номерлы, 2021 елның 9 мартындагы 535 номерлы, 2021 елның 18 маендагы 1205 номерлы, 2021 елның 7 декабрендәге 3252 номерлы, 2022 елның 3 ноябрендәге 3825 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 2(1) пункт өстәргә:

«2(1). Электромобильләрне парковкалау рөхсәтләренең гамәлдә булу вакыты электромобильләрнең парковка рөхсәтләре реестрына кертелгән көннең икенче көненнән алып ике ел тәшкил итә дип билгеләргә»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 2(2) пункт өстәргә:

«2(2). Электромобильгә парковка рөхсәте турында язма кертү турында элек бирелгән хәбәрнамәләрнең, электромобильгә парковка рөхсәте турындагы язманы үзгәртү һәм электромобильгә парковка рөхсәтенең гамәлдә булу вакытын озайту турында белешмәләрнең гамәлдә булу вакыты әлеге карар гамәлгә кергән вакыттан алып ике ел тәшкил итә дип билгеләргә».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә;

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**